**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении Порядка освобождения граждан Российской Федерации, заключивших контракт о прохождении военной службы в связи с призывом на военную службу по мобилизации в Вооруженные Силы Российской Федерации, и членов их семей от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 31 декабря 2022 года № УП-940 «Об утверждении Порядка освобождения граждан Российской Федерации, заключивших контракт о прохождении военной службы в связи с призывом на военную службу по мобилизации в Вооруженные Силы Российской Федерации, и членов их семей от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме» следующие изменения:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Об утверждении Порядка освобождения отдельных категорий граждан Российской Федерации от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме, установленных жилищным законодательством Российской Федерации»;

б) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Утвердить прилагаемый Порядок освобождения отдельных категорий граждан Российской Федерации от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме, установленных жилищным законодательством Российской Федерации.»;

в) Порядок освобождения граждан Российской Федерации, заключивших контракт о прохождении военной службы в связи с призывом на военную службу по мобилизации в Вооруженные Силы Российской Федерации, и членов их семей от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения платы за жилое помещение и коммунальные

услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме (далее – Порядок) изложить в новой редакции согласно приложению.

2. Установить, что действие Порядка в редакции настоящего Указа распространяется на правоотношения, возникшие с 24 февраля 2022 года.

3. Настоящий Указ вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
28 сентября 2023 года
№ 680

Приложение
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «28» сентября 2023 года
№ 680

**Порядок**
**освобождения отдельных категорий граждан Российской Федерации от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения платы за жилое помещение и коммунальные услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме, установленных жилищным законодательством Российской Федерации**

1. Настоящий Порядок в соответствии со статьей 9[1] Федерального закона от 14 марта 2022 года № 58-ФЗ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (далее – Федеральный закон) определяет процедуру освобождения отдельных категорий граждан Российской Федерации от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения ими платы за жилое помещение и коммунальные услуги, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирном доме, установленных жилищным законодательством Российской Федерации (далее – обязательные платежи), на территории Республики Татарстан.

2. В соответствии со статьей 9[1] Федерального закона от начисления пеней в случае несвоевременного и (или) неполного внесения обязательных платежей (далее – начисление пеней) освобождаются:

а) граждане Российской Федерации (далее – граждане), призванные на военную службу по мобилизации, – на период прохождения ими военной службы;

б) граждане, проходящие военную службу в Вооруженных Силах Российской Федерации по контракту, граждане, проходящие военную службу (службу) в войсках национальной гвардии Российской Федерации, в воинских формированиях и органах, указанных в пункте 6 статьи 1 Федерального закона от 31 мая 1996 года № 61-ФЗ «Об обороне», при условии их участия в специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Херсонской области и Запорожской области – на период их участия в специальной военной операции;

в) граждане, заключившие контракт о добровольном содействии в выполнении задач, возложенных на Вооруженные Силы Российской Федерации, в период мобилизации, в период действия военного положения, в военное время, при возникновении вооруженных конфликтов, при

проведении контртеррористических операций, а также при использовании Вооруженных Сил Российской Федерации за пределами территории Российской Федерации, – на период действия указанного контракта;

г) граждане, проходящие военную службу в пограничных органах федеральной службы безопасности и выполняющие (выполнявшие) задачи по отражению вооруженного вторжения на территорию Российской Федерации, выполняющие (выполнявшие) задачи в ходе вооруженной провокации на Государственной границе Российской Федерации и приграничных территориях субъектов Российской Федерации, прилегающих к районам проведения специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области, а также обеспечивающие (обеспечивавшие) проведение специальной военной операции на указанных приграничных территориях субъектов Российской Федерации, проходящие военную службу (службу) в войсках национальной гвардии Российской Федерации и оказывающие (оказывавшие) содействие пограничным органам федеральной службы безопасности по отражению вооруженного вторжения на территорию Российской Федерации, а также в ходе вооруженной провокации на Государственной границе Российской Федерации и приграничных территориях субъектов Российской Федерации, прилегающих к районам проведения специальной военной операции на территориях Украины, Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области, – на период выполнения ими указанных задач;

д) совместно проживающие с гражданами, указанными в подпунктах «а»–«г» настоящего пункта, супруги, дети, родители, а также другие родственники, нетрудоспособные иждивенцы и иные граждане, признанные членами семьи (далее – члены семьи), – на период, установленный для граждан, указанных в подпунктах «а»–«г» настоящего пункта.

3. Мера социальной поддержки, указанная в пункте 2 настоящего Порядка, предоставляется на периоды и гражданам, указанным в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, независимо от того, кто из них является нанимателем (собственником) жилого помещения, независимо от места их регистрации по месту жительства и (или) месту пребывания, а также независимо от вида жилищного фонда и распространяется только на одно жилое помещение (по выбору граждан, указанных в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка).

4. Для освобождения от начисления пеней граждане, указанные в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, подают заявление в организации, получающие обязательные платежи на основании договоров, заключенных с лицами, осуществляющими соответствующие виды деятельности (управляющая организация, товарищество собственников жилья, жилищный кооператив или иной специализированный потребительский кооператив, созданный в целях удовлетворения

потребностей граждан в жилье в соответствии с федеральным законом о таком кооперативе, ресурсоснабжающая организация, специализированная некоммерческая организация, которая осуществляет деятельность, направленную на обеспечение проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, региональный оператор по обращению с твердыми коммунальными отходами) (далее – организация).

5. Заявление подается гражданами, указанными в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка (или их уполномоченными представителями) (далее – заявитель), в организации в письменной форме в двух экземплярах с приложением следующих документов:

а) копия документа, удостоверяющего личность заявителя;

б) копии документов, подтверждающих статус члена семьи (для граждан, указанных в подпункте «д» пункта 2 настоящего Порядка);

в) копия документа, подтверждающего полномочия представителя (в случае подачи заявления уполномоченным представителем);

г) письменное согласие на обработку персональных данных заявителя в соответствии со статьей 9 Федерального закона от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

Граждане, указанные в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, вправе приложить документы, подтверждающие в соответствии с законодательством Российской Федерации участие граждан, указанных в подпунктах «а»–«г» пункта 2 настоящего Порядка, в специальной военной операции (выполнение ими задач).

6. Копии документов предъявляются в организацию в одном экземпляре с предъявлением оригиналов. Оригиналы документов не предъявляются, если их копии заверены органом (учреждением), выдавшим оригинал документа, или нотариально.

Копии документов после проверки их соответствия оригиналам заверяются лицом, принимающим документы, оригиналы документов возвращаются заявителю.

7. Лицо, осуществляющее прием заявления и прилагаемых к нему копий документов, незамедлительно регистрирует заявление и возвращает заявителю второй экземпляр заявления с отметкой о его получении.

8. Заявление и копии документов, прилагаемые к заявлению, могут направляться в организацию по почте. В этом случае копии документов должны быть заверены органом (учреждением), выдавшим оригинал документа, или нотариально, за исключением копии документа, удостоверяющего личность заявителя.

9. Организация в течение трех рабочих дней со дня регистрации заявления обязана рассмотреть его и принять решение об освобождении от начисления пеней или об отказе в освобождении от начисления пеней.

10. Основаниями для отказа в освобождении от начисления пеней являются:

представление неполного комплекта документов, указанных в пункте 5 настоящего Порядка;

представление документов, предусмотренных пунктом 5 настоящего Порядка, содержащих недостоверные сведения.

11. Граждане, указанные в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, обязаны информировать организацию, освободившую их от начисления пеней, о завершении периода, указанного в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, не позднее 30 календарных дней со дня его прекращения.

12. В случае невозможности подачи заявления в периоды, предусмотренные в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, граждане, указанные в подпунктах «а»–«д» пункта 2 настоящего Порядка, могут обратиться в организацию с заявлением о списании начисленных пеней с приложением документов, предусмотренных пунктом 5 настоящего Порядка, в течение трех лет со дня окончания указанных периодов.

13. При наличии технической возможности взаимодействие организации и заявителя может осуществляться в электронной форме.

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен раслау турында» 2022 елның 31 декабрендәге ПУ-940 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең аерым категория гражданнарын торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, Россия Федерациясенең торак турындагы законнарында билгеләнгән пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен раслау турында»;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясенең аерым категория гражданнарын торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, Россия Федерациясенең торак турындагы законнарында билгеләнгән пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен расларга.»;

в) Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын, торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән азат итү тәртибен (алга таба – Тәртип) кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указдагы редакциясендә Тәртипнең гамәле 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 28 сентябрь
№ 680

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «28» сентябрендәге
680 номерлы Указына
кушымта

**Россия Федерациясенең аерым категория гражданнарын торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, Россия Федерациясенең торак турындагы законнарында билгеләнгән пенялар исәпләүдән азат итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртиптә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $9^1$ статьясы нигезендә Россия Федерациясенең аерым категория гражданнарын торак һәм коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь төзекләндерү өчен (алга таба – мәҗбүри түләүләр) үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең торак турындагы законнарында билгеләнгән пенялар исәпләүдән азат итү процедурасы билгеләнә.

2. Федераль законның $9^1$ статьясы нигезендә мәҗбүри түләүләрне үз вакытында һәм (яисә) тулысынча түләмәүләре очрагында, пенялар исәпләүдән (алга таба – пенялар исәпләү) түбәндәгеләр азат ителә:

а) мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гражданнар) – алар хәрби хезмәт узган чорда;

б) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәт узучы (хезмәт итүче) гражданнар, алар Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон өлкәсе һәм Запорожье өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашулары очрагында – алар махсус хәрби операциядә катнашкан чорда;

в) мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, хәрби гамәлләр вакытында, кораллы каршылыклар туганда, террорчылыкка каршы операцияләр уздырганда, шулай ук Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрен кулланганда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле

рәвештә ярдәм итү турында контракт төзегән гражданнар – әлеге контракт гамәлдә булган чорда;

г) федераль куркынычсызлык хезмәтенең чик буе органнарында хәрби хезмәт узучы һәм Россия Федерациясе территориясенә кораллы һөҗүмгә каршы тору бурычын үтәүче (үтәгән), Россия Федерациясенең Дәүләт чигендә һәм Россия Федерациясе субъектларының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция уздырыла торган районнар янында урнашкан чик яны территорияләрендә кораллы каршылыклар китереп чыгару омтылышларын бетерү барышында бурычлар үтәүче (үтәгән), шулай ук Россия Федерациясе субъектларының әлеге чик яны территорияләрендә махсус хәрби операция уздыруны тәэмин итүче (тәэмин иткән), Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хәрби хезмәт узучы (хезмәт итүче) һәм Россия Федерациясе территориясенә кораллы һөҗүмгә каршы торуда, шулай ук Россия Федерациясенең Дәүләт чигендә һәм Россия Федерациясе субъектларының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция уздырыла торган районнар янында урнашкан чик яны территорияләрендә кораллы каршылыклар китереп чыгару омтылышларын бетерү барышында федераль куркынычсызлык хезмәтенең чик буе органнарына ярдәм итүче (ярдәм иткән) гражданнар – алар әлеге бурычларны үтәгән чорда;

д) әлеге пунктның «а»–«г» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның алар белән бергә яшәүче хатыны, ире, балалары, ата-анасы, шулай ук башка туганнары, аларның тәрбиясендә торучылар һәм гаилә әгъзалары дип танылган башка гражданнар (алга таба – гаилә әгъзалары) – әлеге пунктның «а»–«г» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өчен билгеләнгән чорда.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы аларның кайсысы торак йортның нанимателе (милекче) булуына, тору урыны һәм (яисә) яшәү урыны буенча кайда теркәлүенә, шулай ук торак фондының төренә карамастан, әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарга да бирелә һәм бары тик бер торак йортка гына (әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның сайлавы буенча) карый.

4. Әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар пенялар исәпләүдән азат ителү өчен тиешле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы затлар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен мәҗбүри түләүләр ала торган оешмаларга (идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яисә махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы турында федераль закон нигезендә гражданнарның торакка ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында төзелгән башка шундый кооператив, ресурслар белән тәэмин итүче оешма, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь

төзекләндерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган махсуслаштырылган оешма, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторы (алга таба – оешма) гариза бирә.

5. Әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар (яисә аларның вәкаләтле вәкилләре) (алга таба – гариза бирүче) тарафыннан оешмаларга түбәндәге документлар теркәлгән гариза язма рәвештә, ике нөсхәдә бирелә:

а) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның күчермәсе;

б) гаилә әгъзасының статусын раслый торган документларның күчермәләре (әлеге Тәртипнең 2 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар өчен);

в) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсе (гариза вәкаләтле вәкил тарафыннан бирелгән очракта);

г) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә язма рәвештә бирелгән ризалык.

Әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«г» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашуларын (бурыч үтәүләрен) раслаучы документларны теркәп бирергә хокуклы.

6. Оешмага документларның күчермәләре төп нөсхәләре белән бергә бер нөсхәдә тапшырыла. Документларның төп нөсхәләре, аларның күчермәләре документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) яисә нотариус тарафыннан таныкланган очракта, тапшырылмый.

Документларны кабул итүче зат документларның күчермәләрен аларның төп нөсхәгә туры килү-килмәвен тикшергәннән соң раслый һәм документларның төп нөсхәләрен гариза бирүчегә кире кайтара.

7. Гаризаны һәм аңа теркәп бирелгән документларның күчермәләрен кабул итүче зат кичектермәстән гаризаны терки һәм гаризаның икенче нөсхәсен, аны кабул итү турында билге куеп, гариза биргән затка кире кайтара.

8. Гариза һәм гаризага теркәп бирелгән документларның күчермәләре оешмага почта аша җибәрелергә мөмкин. Бу очракта документларның күчермәләре, гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ күчермәсеннән тыш, документның төп нөсхәсен биргән орган (учреждение) яисә нотариус тарафыннан таныкланырга тиеш.

9. Гаризаны теркәгән көннән соң өч эш көне дәвамында оешма аны карап тикшерергә һәм пенялар исәпләүдән азат итү яисә пенялар исәпләүдән азат итүдән баш тарту турында карар кабул итәргә тиеш.

10. Пенялар исәпләүдән азат итүдән баш тарту өчен түбәндәге шартлар нигез була:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы

булмаган комплектын тапшыру;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы.

11. Әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар аларны пенялар исәпләүдән азат иткән оешмага әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән чор тәмамлану турында, ул тәмамланган көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән чорларда гариза бирү мөмкин булмаган очракта, әлеге Тәртипнең 2 пункты «а»–«д» пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар әлеге чорлар тәмамланган көннән өч ел дәвамында оешмага әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, исәпләнгән пеняларны исәптән чыгару турында гариза бирә ала.

13. Техник мөмкинлекләр булганда, оешма һәм гариза бирүче арасындагы хезмәттәшлек электрон рәвештә алып барылырга мөмкин.

---